РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2018 ел г. Альметьевск № 2224

2019 елга Әлмәт муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләре буенча балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында

29 декабрь 2012 елы № 273-ФЗ “Россия Федерациясендә мәгариф турында” гы Федераль Законның 99 нчы маддәсе, 06 октябрь 2003 елы №131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” гы Федераль Законның 15 маддәсе, 1 бүлеге, 11 пункты, 2009 ел 31 декабрендә кабул ителгән №939 “Татарстан Республикасының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләре буенча балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртипләре турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Әлмәт муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга расларга:

- Әлмәт муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология,хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни,техник һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләре

Зак. № 3063

буенча балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга бүленгән норматив чыгымнарны ( Кушымта №1);

- туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләре буенча балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Тәэмин итүне Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә (Шәйдуллина З.Р.):

- балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен финанслауны әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнарына бәйле рәвештә;

- әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеге чоры дәвамындагы норматив чыгымнарны, хезмәт законнары һәм башка норматив-хокукый актлар тәртибендә тормышка ашырыла торган өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер периодта яңадан карарга.

3. Район башкарма комитетеның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырырга, PRAVO.TATARSTAN.RU.Татастан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматлар порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2019 елның 01 январеннән соң барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.В. Лаптевага йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Кушымта №1
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
"20" декабрь 2018 №2224
карары белән расланды

Әлмәт муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешләре буенча балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | 1 укучыга бер елга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укуның беренче елы | Укуның икенче елы | Укуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

Район башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева